**Публичное выступление**
**Халык алдындагы чыгыш - 2016-17ел, январь**

Татар Кандызы урта мәктәбе -- авылыбызның белем һәм тәрбия үзәге булып тора. Аның **320 урынлы** яңа бинасы 1984 нче елда салынган. Бинаның мәйданы **2203 кв. м.**, ә мәктәп территориясенең мәйданы **16467 кв.м.** тәшкил итә: анда спорт мәйданчыгы, тәҗрибә участогы, теплица, җимеш бакчасы, хоккей мәйданчыгы бар. Мәктәптә барлык **санитар-гигиена**, **янгын куркынычсызлыгы** кагыйдәләре үтәлә.

Бүгенге көндә мәктәптә **84 бала белем һәм тәрбия ала**:

- ✓ **19 бала**- мәктәпкәчә яшьтәге балалар төркемендә (дошкольная группа), шуның **2 се** икешәр сәг. кә беренче сыйныфка әзерләнү өчен килә, әле тагын ике бала хәзергесе көндә медосмотр үтеп йөри, заявлениеләр бирделәр.
- ✓ **21 бала**- башлангыч сыйныфта
- ✓ **33 бала**-урта сыйныфта
- ✓ **9 укучы**- югары сыйныфта укыйлар

**15 укытучы укыта, 2 тәрбияче, 12 техперсонал** эшли.( Барлыгы-29 эшче )

**Мәктәпнең 4 баскычтан торган лицензиясе (дошкольное образование, начальное образование, основное образование, среднее образование) бар**.

Мәктәпнең **материаль-техник база**сын тиешле дәрәҗәдә саклау өчен байтак эшләр башкарылды: мәктәпкә ремонт үткәрелде.

**Мәктәптә укыту-тәрбия процессын** алып бару өчен барлык **шартлар** да тудырылган: 13 укыту кабинеты, мастерской, спортзал, актовый зал, картиналар галереясы, икмәк һәм туган якны өйрәнү музее, информатика кабинеты, китапханә, ашханә эшли. Ашханәдә бөтен бала да кайнар аш белән тәэмин ителә. Ашау өчен дәүләт биргәннән тыш ата-аналардан көненә 12 сум җыябыз.

Мәктәп **педагогик кадрлар** белән тиешенчә тәэмин ителгән. 15укытучы, шуларның 13- югары белемле, берсе читтән торып укый. Ел саен укытучылар үзбелемнәрен күтәрү өстендә эшлиләр, аттестация үтәләр, курсларда укыйлар.
**Югары категорияле-4 укытучы**
**1 категорияле - 9 укытучы**
**Әлегә категориясез -2 укытучы**

Коллектив дус, тату, бердәм булып бик күп еллардан бирле эшләп килә. **Уку-укыту процессын** укытучылар төрле методик алымнар һәм инновацион технологияләр кулланып башкара. Сәләтле, талантлы һәм укуны авыррак үзләштерүче укучылар белән индивидуаль эш алып барыла. Уку **өлгереше** 100%, **белем сыйфаты** 50 %.

Мәктәп укучыларыбыз район һәм республика, россия масштабында үткәрелгән төрле **<u>конкурс</u>** һәм **о<u>лимпиада</u>**ларда, фәнни –практик конференцияләрдә катнашып призлы урыннарга лаек булды.
Район **предмет олимпиадаларында** призлы урыннар яуладылар: **Биология-2 урын ( 7 кл.- Валиева Ландыш, укытучы Вагизова Г.З.)Тат.теле-2 урын ( 8 кл.- Ахметзянова Кадрия, укытучы Халиуллина Р.Н.)Тат.теле-2 урын ( 11 кл. Халиуллина Миләүшә, укытучы Гиззатуллина З.М.)**

## <u>РАЙОН НӘТИҖӘЛӘРЕ</u>

1. **“Боз өстендә сак бул” рәсем конкурсында** - 4нче сыйныф укучылары актив катнашты (ук. Нургалиева Р.М.) призлы урыннар алдылар, Самигуллин Альмирның эше республикага җибәрелде.
2. **“Киләчәккә билет” –сочинениеләр конкурсында** Ахметзянова Кадрия, Заниева Алсу ( ук. Халиуллина Р.Н.), Габдрахманова Лилия, Галимзянов Рәмзил, Хуснутдинова Регина (ук.Гиззатуллина З.М.) призлы урыннар алдылар . Бер укучыбызның эше республикага җибәрелде.
3. “**Ана бөек исем” район конкурсы**- 4 нче сыйныф укучысы , Самигуллин Альмир әнисе белән катнашты, 1 нче урынга лаек булды. (ук. Нургалиева Р.М.)
4. **Коррупциягә каршы көрәш** темасына үткәрелгән рәсем конкурсында катнашып 3 нче сыйныф укучысы Вагизов Рәмзил- 2 меңлек сертификатка ия булды
5. **К Тинчуринның 129 еллыгына, театрның 100 еллыгына багышланган конкурста** мәктәпнең “Энҗе бөртекләре” театр коллективы 1 урынга лаек булды. Әсәрдән монолог номинациясендә- Заниева Алсу -2 нче урында, спектакльдан җыр номинациясендә- Нуретдинов Айдар һәм Ахметзянова Кадрия 3 урын алды.
6. **<u>РЕСПУБЛИКА НӘТИҖӘЛӘРЕ сөендерә:</u>**
   1. **- Кече яшьтәге мәктәп укучылары өчен оештырылган С.Морозов исемендәге IX республика конференциясендә** катнашып . 3 нче сыйныф укучысы Хайбрахманов И.М. 3 урынга лаек булды ( ук. Хусаинова Р.И.) , ә 4 нче сыйныф укучысы Нуретдинов Рифат “Иҗат һәм эзләнү” дипломына лаек булды (ук. Нургалиева Р.М.)
   2. **Сирин Батыршин иҗатына багышлан республика фәнни-гамәли конференциядә** 8 кл укучысы Ахметзянова Кадрия-2 урынга лаек булды ( ук. Халиуллина Р.Н.) , Халиуллина Миләүшә- сертификат белән бүләкләнде ( ук. Гиззатуллина З.М.).
   3. “Энҗе бөртекләре” театр коллективы **“Сәйяр” театр фестиваль-**бәйгесенең зона (төбәк) этабында (Әлмәт шәһәре) уңышлы чыгыш ясап башкалабызның К.Тинчурин исемендәге театрына бүләкләү тантанасына чакырылды. Театр коллективы Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән Министрлыгының дипломына лаек булды.

**Мәктәп укытучыларыбыз** үзләре дә эш тәҗрибәләрен матбугат битләрендә бастыралар, һәртөрле конкурсларда катнашып тәҗрибәләрен баеталар һәм категорияләрен күтәрәләр **. “Ел укытучы-2017”район конкурсында катнашып башлангыч сыйныф укытучысы Нургалиева Р.М**. “Осталык һәм профессиональлек” номинациясендә җиңү яулады.

Чыгарылыш сыйныф укучыларын **<u>бердәм дәүләт имтиханнарына</u>** әзерләү тиешле дәрәҗәдә алып барыла. 2015-2016 нче уку елында 4 укучы укыды, барысы да бердәм дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшырып аттестат алды..

**2015-2016 уку елы.** 9 нчы сыйныф укучыларының имтихан нәтиҗәләре **(ОГЭ):**

| Предмет | Уку-чы са-ны | Әзерләүче укытучы | Өлгe-реш | СЫЙФАТ | | УРТАЧА БИЛГЕ | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | мәктәптә | районда | мәкт | районда | по РТ |
| Математика | 8 | Тахаутдинова Г.Г. | 100 % | 75 | | 3,87 | 3,72 | 3,87 |
| Русский язык | 8 | Фархутдинова А.Г. | 100 % | 25 | | 3,2 | 3,91 | 4,07 |
| География | 1 | Гайфуллина С.Ш. | 100 | 100 | | 4 | | |
| Биология | | Вагизова Г.З. | 50 | 0 | | 2,7 | | |
| обществ | 4 | Ахметзянова Р.Г. | 50 | 50 | | 3 | | |
| **Татар теле (ЕРТ)** | **8** | **Гиззатуллина З.М.** | **100 %** | **71,4** | | **3,7** | | |

Иң яхшы күрсәткечләр- татар теленнән бердәм республика тестлары нәтиҗәсе. Безнең мәктәп районда икенче урында, бераз Чүте мәктәбеннән калыша,уку сыйфаты 80%, район 56%, барлык биремнәрне үтәү %-71, районда-58. Бу безнең укытучыларыбызның тырышып эшләү нәтиҗәсе. Рус теленнән 4% ка гына калыштык, ә математикадан әле эшлисе бар.

**<u>Бердәм дәүләт имтиханнары (ЕГЭ) нәтиҗәләре</u>**

| Год | Количество сдававших | 2016 год | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | школа | район | сравнение | РТ | сравнение |
| русский язык | 4 | 65,7 | 72,20 | -6,50 | 73,04 | -7,34 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| математика(профиль) | 3 | 33,7 | 56,12 | -22,4 | 52,97 | -19,27 |
| математика(базовый) | **4** | **4,5** | **4,38** | **+0,12** | **4,33** | **+0,17** |
| физика | 2 | 45,5 | 49,1 | -3,6 | 53,45 | -7,95 |
| обществознание | 3 | 48 | 58,7 | -10,7 | 57,27 | -17,27 |

ЕГЭ буенча күрсәткечләр түбәнрәк. Эшлибез, тырышабыз. Быел яхшырак булыр дип өметләнәбез!

Мәктәптә физик тәрбия өчен бөтен уңайлыклар тудырылган спортзал эшли. “Волейбол”,”Баскетбол” секцияләре үткәрелә.Мәктәп янында үз көчебез белән төзелгән хоккей мәйданчыгы эшли. Укучылар бик яратып йөриләр.

Мәктәптә **тәрбия эшләре** укучыларны әдәпле, тәртипле, әхлаклы, белемле итү максаты белән алып барыла. Класс сәгатьләре, тәрбия чаралары, конкурслар, спорт ярышлары, бәйрәмнәр үткәрү традициягә кертелгән.

Туган якка мәхәббәт, хезмәт кешесенә ихтирам, илебезнең тарихы, культурасы өйрәнү максатында “Икмәк музее”, Картиналар галереясы эшләп килә. Андагы икмәк турында искиткеч бай материал авылыбызның алдынгы игенчеләре, хезмәт ияләре хакындагы материал һәрвакыт тулыландырылып торыла. Музеебызга төрле җирләрдән экскурсияләргә киләләр.

Якын киләчәктә укучылар саны артыр дип торабыз. Чөнки авылыбызның буш йортларына яшь гаиләләр кайтып урнашты.

| **Год** | **Количество будущих первоклассников** | **Общее кол-во учащихся+воспитанников дошкольной группы** |
|---|---|---|
| **2016-2017** | **3** | **64+19= 83** |
| **2017-2018** | **7** | **65+20=85** |
| **2018-2019** | **9** | **67+20=87** |
| **2019-2020** | **9** | **66+20=87** |

**Мәктәп алдында торган проблемалар:**

Мәктәп искерә таушала бара, мәктәп салынганга быел 33 ел тулачак.

- Түбәгә капиталь ремонт

- Кательнига запас насос
- Җылылык батареяларын алыштырырга
- Тәрәзәләр алыштырырга кирәк

Хөрмәтле авылдашлар! Игътибарыгыз өчен рәхмәт!